**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д. 22, г. Азнакаево, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитетлар**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. / факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 11 » 09 2018 ел № 250

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 20 июнендәге 139 номерлы «Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогында «БАРС» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе төзү турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында» Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы «БАРС» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2018 елның 01 июнендәге 10-06/8579 номерлы йөкләмәсе нигезендә карар итәм:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 20 июнендәге 139 номерлы «Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогында «БАРС» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе төзү турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында» Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы «БАРС» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу

6.1. Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә, учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясарга мөмкин һәм шул ук вакытта учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм хокуклары арасында каршылык барлыкка килергә мөмкин яисә туарга мөмкин булган һәм ул

хезмәткәр булып торган учреждениенең мәнфәгатьләре законнары белән учреждениенең мөлкәтенә һәм (яисә) эшлекле абруена зыян китерергә сәләтле.

6.2. Үз хезмәт бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган учреждение хезмәткәре шәхси кызыксынуы дигәндә, акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар, яисә милек характерындагы хезмәтләр рәвешендә яисә өченче затлар өчен керемнәрне хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә учреждение хезмәткәре тарафыннан алу мөмкинлеге аңлашыла.

6.3. Учреждение директоры гамәлгә куючыга вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

6.4. Учреждение хезмәткәре вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында учреждение директорына хәбәр итәргә тиеш. Учреждение директорына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган белешмәләр исемлеге, әлеге белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе учреждение директоры тарафыннан билгеләнә.»;

6, 7, 8 һәм 9 бүлекләрне 7, 8, 9 һәм 10 дип санарга.

2. Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогында «БАРС» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директорына (Сәлимов М.Ф.) уставка кертелгән үзгәрешләрне гамәлдәге законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алырга.

3. Әлеге карарны «веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы: http//pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakaevo адресы буенча Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. tatar.ru/

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов